РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » 01 2022 г. № 40

2022 елда Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
гомуми белем бирү учреждениеләрендә
укучылар туклануын оештыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 06.09.2021 ел, 826 номерлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 гыйнварыннан расларга:
- 5-11 сыйныфлар өчен гомуми белем бирү учреждениесенең бер укучысы өчен туклану бәясен 56 сум 30 тиен күләмендә, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга көненә 8 сум 30 тиен күләмендә субсидияне;
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 48 сум 00 тиен күләмендә ата-аналар взносы суммасын;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныфлар өчен көненә бер укучыга 53 сум 30 тиен күләмендә туклану бәясен, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга көненә 8 сум 30 тиен күләмендә субсидияне;
- уку чорында бер укучыга көнгә 45 сум 00 тиен күләмендә ата-ана взносы суммасын;

2. Якынча унике көнлек менюны расларга. Бер көнлек менюның бәясе туклану продуктларына билгеләнгән бәяләргә карап раслана.

3. Башлангыч гомуми белем алучы балаларны бушлай бер тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны ташламалы тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Финанс - бюджет палатасына «Мәгариф» тармагы буенча 2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында шушы максатларда каралган акчалар чикләрендә белем алучы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен тукландыруга чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2021 елның 24 декабрендәге 1088 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Башк. С.А. Абрамов
(885593)2-71-00

Кушымта 1
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
"___"___________ 2022 ел №___

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыру тәртибе турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның кайнар туклануын оештыру максатларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен эшләнде:

Россия Федерациясе Президентының 1992елның 5 маендагы «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 431 номерлы Указы нигезендә, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән булган укучыларны ике тапкыр түләүсез туклану (иртәнге һәм төшке аш) белән тәэмин итәргә. Әлеге категориядәге укучыларга ташламалы туклану, гомуми белем бирү учреждениеләрендә өч һәм аннан да күбрәк бала белем алса, бирелә;

-ата-аналары 1 нче һәм 2 нче инвалидлык төркеменә ия булган балаларга;

- опекада торучы балаларга (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органнары белән килештереп);

Әлеге категориягә керүче балаларга адреслы социаль ярдәм 2022 елга гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклану (әбәд ашы) өчен ата-аналар түләвеннән өлешчә азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 пункты нигезендә, ташламалы туклану сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, инвалид балаларга бирелә.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларны бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин итү өчен нигез булып тора:

- белем алучыны оешмага кабул итү турында учреждение боерыгы;

- учреждениенең туклану белән тәэмин итү турындагы боерыгы (алга таба - Карар);

- укучының оешмада белем алу статусын раслый торган документ:

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучының - Татарстан Республикасы психологик-медицина-педагогика комиссиясе (алга таба ПМПК) тарафыннан бирелгән бәяләмәсе нигезендә, ул укучыларда махсус шартлар тудырмыйча белем алуга комачаулык иткән физик, психик, интеллектуаль, сенсор яисә башка тайпылышлар булуны раслый торган бәяләмә;

Инвалид баланың - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә.

2. Ташламалы туклану җирле бюджет акчалары хисабыннан Урыссу шәһәр тибындагы поселогының гомуми белем бирү учреждениеләренең бер укучысына көнгә 56 сум 30 тиен исәбеннән һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең бер укучысына көнгә 53 сум 30 тиен исәбеннән оештырыла.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар тукландыруны оештыру өчен гомуми белем бирү учреждениесенең директоры, педагогик коллектив составыннан укучыларны тукландыруны оештыруга җаваплы зат һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссия төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә өч кеше булырга тиеш.

Комиссия ата-аналардан яки аларны алмаштыручылардан гариза кергән көннән алып 3 эш көне эчендә җыела.

Комиссия карары ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан кергән гаризаларны карый башлаганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

4. Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан, документларны (белешмәләр: гаилә хәле турында, гомуми белем бирү учреждениесендә укуы турында, инвалидлык турында белешмә (таныклык) күчермәсе, опека һәм попечительлек органының опека һәм попечительлек билгеләү турындагы карары күчермәсе) раслый торган ташламалы туклану белән тәэмин итүгә гариза кабул итәләр;

- гариза алынганнан соң өч көн эчендә Комиссия каравына җибәрелә;

- сыйныфта категория буенча укучыларның туклануын исәпкә алып баралар;

- укучылар һәм ата-аналар арасында мәктәп укучыларын тулысынча тукландыру кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;

- барлык сыйныф укучыларының да ашханәгә кереп туклануын тикшереп тора;

- ашханәдә сыйныф укучылары ашаган вакытта анда булалар.

5. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре:

6.1. Укучыларны ташламалы туклану белән тәэмин итү буенча боерыклар чыгара.

6.2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУга категорияләре буенча укучылар исемлеген тәкъдим итәләр.

7. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ укучыларны туклandыруны оештыру, ашарга әзерләү технологиясен үтәү, азык-төлек блокларында әзер ашамлык чыгышына һәм санитар нормаларны үтәү мәсьәләләренә кураторлык итә.